**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№3546**
**10.07.2019**

Татарстан Республикасы көнен һәм Яр Чаллы шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чаралар үткәрү турында

Татарстан Республикасы көненең һәм Яр Чаллы шәһәре көненең мөһим иҗтимагый-сәяси әһәмиятен исәпкә алып, аларны бәйрәм итүгә багышланган чараларны югары дәрәҗәдә әзерләү һәм үткәрү максатында

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Татарстан Республикасы көнен һәм Яр Чаллы шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларны 2019 елның 10 августыннан 30 августына кадәр үткәрергә.
2. Чараларны үткәрү урыннарын билгеләргә:
1) «Азатлык» мәйданы;
2) «Җиңү» мәдәният һәм ял паркы;
3) ГЭС поселогының Мәдәният һәм ял паркы;
4) «Сидоровка» паркы;
5) «Яр буе» паркы, Мәйдан;
6) Шәһәр ипподромы;
7) Боровецкий бульвары;
8) Кереселидзе бульвары;
9) Тинчурин бульвары;
10) Энтузиастлар бульвары;
11) Г.Тукай яр буе;
12) Ф.Табиев исемендәге яр буе;
13) «Төзүче» стадионы;
14) Г.Тукай исемендәге сквер;
15) «Тридевятое царство» скверы;
16) Тантана сарае;
17) «КАМАЗ» мәдәният сарае.
3. Расларга:
1) Татарстан Республикасы көнен һәм Яр Чаллы шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча;
2) Татарстан Республикасы көнен һәм Яр Чаллы шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган чараларга әзерлек һәм аларны үткәрү буенча оештыру чаралары планын, 2 нче кушымтада каралганча;

3) Татарстан Республикасы көнен һәм Яр Чаллы шәһәре көнен бәйрәм итүгә багышланган мәдәни-массакүләм һәм спорт чаралары планын, 3 нче кушымтада каралганча.

4. Тәкъдим итәргә:

1) Яр Чаллы шәһәре буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы идарәсенә (Н.Д. Закирова) чаралар үткәрү урыннарында гражданнар иминлеген һәм җәмәгать тәртибен тәэмин итүдә ярдәм күрсәтергә;

2) Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Яр Чаллы шәһәре буенча сәламәтлек саклау идарәсенә (Н.Ш. Фатыйховка) массакүләм чаралар үткәрү урыннарында ашыгыч медицина ярдәме бригадаларының һәм фельдшер бригадаларының дежур торуын оештырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев